ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШИШИНЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ШЕҢШЕҢӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
«23» апрель 2020 ел

КАРАР
№ 7

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге башкарма комитетының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында**

Гамәлдәге законнардагы үзгәрешләр белән бәйле рәвештә, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

1.1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге башкарма комитетының 25.09.2015 ел, № 17 «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге территориясендә адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карары;

1.2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге башкарма комитетының 01.08.2011 № 39 «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Шеңшеңәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә капиталь төзелеш объектына почта адресын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карары»;

1.3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге башкарма комитетының 15.06.2012 № 10 «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Шеңшеңәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карары.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми baltasi.tatarstan.ru сайтында бастырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Шеңшеңәр авыл җирлеге башлыгы: Р.Х.Салихҗанов